# Авылым

1) Авылыма кайттым, җәйге авыл
   Аеруча якын күңлемә.
   Яланаяк чирәмендә йөрим,
   Яратып су керәм күлендә.

Кушымта:
   Әй, авылым, сиңа кайткан саен.
   Йөрәгемдә яңа җыр туа.
   Синдә генә күңлем чиксез шатлык,
   Тынычлык, сафлык белән тула.

2) Урманында каен җиләкләре,
   Шундый тәмле, телне йотарлык.
   Болынында үскән чәчәкләрнең
   Күплегенә торам таң калып.

3) Авылдагы саф һаваны сулап,
   Атлыйм тик якты уйлар уйлап.
   Үзем мин шәһәрдә яшәсәм дә,
   Авыл җанлы, авыл кызы бугай.